| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» август 2026г. г. Альметьевск №70

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» 2013 елның 11 мартындагы 286 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» 2013 елның 11 мартындагы 286 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының башкарма комитетын Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4 - 2.7, 2.12, 2.13 статьялары, 2.15 статьясындагы 2 өлеше, 2.17, 2.21, 2.22, 3.2 - 3.6, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14 - 3.17, 3.19, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә башкарыла торган муниципаль ташуларга карата) статьяларында каралган (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма үз исемнәре турында белешмәләрне һәм элмә тактада урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуларга карата) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарының үз көчен югалтуын танырга:

- «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 11 мартындагы 286 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 декабрендәге 191 номерлы;

- Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 11 мартындагы 286 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 11 сентябрендәге 247 номерлы.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Г.М. Хәбутдинова